| | |
|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.09.2026 Алабуга шәһәре № 85

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы президиумының «Муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару турында» 2016 елның 13 октябрендәге ПР-26-4 номерлы карарын исәпкә алып һәм Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, җирле үзидарә органнары кабул иткән норматив хокукый актларны исәпкә алуны камилләштерү, унификацияләү һәм системалаштыру, аларның эшчәнлеге турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатларында, Алабуга муниципаль районы Советы

**КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турында Нигезләмәне расларга (кушымта).
2. Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле вәкилләр тарафыннан Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы башкарма комитетының юридик бүлеген һәм Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль актларны теркәү өчен җаваплы вазифаи затларны билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын актуаль хәлдә тоту, шулай ук законнарга туры килми торган муниципаль норматив хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тануны тәэмин итү, законнарга туры килми дип тануны тәэмин итү, эш башкару һәм документлар әйләнеше өчен җаваплы хезмәткәрләргә (затларга) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлегенә муниципаль норматив хокукый

актларга карата килгән мәгълүматны (массакүләм мәгълүмат чараларында, суд актларында, контроль яисә күзәтчелек органнары карарларында, хокукый экспертиза актларында бастырып чыгару һәм башка очракларында) килү көнендә яки күрсәтелгән вакытта тапшыру мөмкин булмаганда, киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыруны тәэмин итәргә йөкләмә бирергә.

4. Муниципаль район составына кергән җирле үзидарә органнарыннан муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында мәгълүматны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар реестрына кертү өчен җыю һәм җибәрү өчен җаваплы вазифаи затка, күрсәтелгән җирле үзидарә органнары белән (килешү буенча) үзара эшчәнлекне оештырырга, муниципаль норматив хокукый актларның җирле дәрәҗәдәге реестрларын алып баруны тәэмин итү максатыннан.

5. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турында» 2017 елның 25 февралендәге 145 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В. Косов